ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

23.12.2024 № 1146

**2024 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы балаларының һәм яшьләренең ялын оештыру турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 05 мартындагы 158 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына үзгәреш кертү хакында» 2024 елның 22 августындагы 680 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2024 елның 09 сентябрендәге 754 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру турында» 2020 елның 29 апрелендәге 346 номерлы карары нигезендә, дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру, балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру, 2025 елда мәктәп каникуллары чорында аларның мәшгульлеген тәэмин итү өчен кирәкле шартлар тудыру максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кушымтада бирелгәннәрне расларга:

1.1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру турында нигезләмә (1 нче кушымта);

1.2. Балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча Биектау муниципаль районы ведомствоара комиссиясе турында нигезләмә (2 нче кушымта);

1.3. Балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча Биектау муниципаль районы ведомствоара комиссиясе составы (3 нче кушымта);

1.4. Балалар һәм яшьләрнең ялы, сәламәтләндерелүе, мәшгульлеге программасы (4 нче кушымта).

2. Роспотребнадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Биектау районында территориаль бүлегенә ташламалы шартларда түбәндәгеләрне үткәрүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә:

балалар ял итү һәм сәламәтләндерү учреждениеләренең гамәлдәге санитария нормаларына һәм кагыйдәләренә туры килүенә санитар-эпидемиологик экспертизаны;

балаларның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү максатларында балалар сәламәтләндерү учреждениеләренә эшкә җибәрелә торган персоналны гигиеник укыту һәм профилактик медицина тикшерүләре, лаборатор-инструменталь тикшеренүләрне.

3. «Биектау районы халкын эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә тәкъдим итәргә:

бюджет йөкләмәләренең бүлеп бирелгән лимитлары һәм чыгымнарны финанслау күләмнәре чикләрендә расланган күләм нигезендә укудан буш вакытта 14 тән 18 яшькә кадәрле балигъ булмаганнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештырырга;

14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаганнарны укудан буш вакытта эшкә урнаштыру мөмкинлеге турында халыкка мәгълүмат бирү эшен оештырырга;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Биектау районы буенча эчке эшләр бүлегенең балигъ булмаганнар эшләре бүлекчәсендә һәм район балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясендә исәптә торучы балигъ булмаганнарны беренче чиратта вакытлыча эшкә урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Балигъ булмаганнарны эшкә урнаштыру чараларын гамәлгә ашырганда 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарның хезмәте өчен түләү федераль законнарда билгеләнгән хезмәткә түләүнең минималь күләме суммасында эш бирүчеләр хисабына гамәлгә ашырыла дигән нигезләмәгә таянырга; гражданнарның күрсәтелгән категориясенә матди ярдәм күрсәтү «Биектау районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе хисабына аена бер кешегә эшсезлек буенча пособиенең 1,5 тапкыр минималь күләменә тигез суммада гамәлгә ашырыла (килешү буенча).

5. «Биектау үзәк хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең баш табибына тәкъдим итәргә:

мәктәп яны лагерьларын медицина кадрлары белән комплектларга;

укудан азат һәм каникуллар вакытында вакытлыча эшкә урнаштыруны рәсмиләштергәндә балигъ булмаганнарның медицина тикшерүен оештыруны тәэмин итәргә;

җәйге стационар һәм мәктәп яны лагерьлары хезмәткәрләрен профилактик максатларда медицина тикшерүләрен амбулатор-поликлиника ярдәме учреждениеләре аша түләүсез үткәрүне тәэмин итәргә.

6. Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча дәүләт янгын күзәтчелеге идарәсенең Биектау районы дәүләт янгын күзәтчелеге бүлегенә сәламәтләндерү учреждениеләрендә һәм массакүләм ял итү урыннарында янгын куркынычсызлыгы таләпләренең үтәлешенә күзәтчелек итүне тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

7. Биектау муниципаль районында Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау бүлегенә тәкъдим итәргә:
«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесенең яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге»

муниципаль казна учреждениесенә авыр тормыш һәм социаль куркыныч ситуацияләрдә булган балалар исемлекләрен шифаханә һәм савыктыру учреждениеләре базаларында ял итү һәм сәламәтләндерүне оештыру өчен бирү.

8. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

2025 елның 5 июненә кадәр көндез булу мәктәп яны лагерьларын ачуны;

лагерьлар ачу, аларны кабул итү, лагерьлар персоналын укыту буенча үз вакытында эшне;

мәктәп балаларын индивидуаль эшкә урнаштыруны, мәктәп яны участокларында эшләүне, балалар мәйданчыкларының эшен контрольдә тотуны;

ятим балаларга, авыр тормыш хәлендә калган балаларга, Россия Эчке эшләр министрлыгының Биектау районы буенча муниципальара бүлегендә балигъ булмаганнар эшләре бүлекчәсендә, район балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясендә исәптә торучы балаларга аеруча игътибарны юнәлтеп, укучыларның хезмәтен һәм ялын оештыруның максималь дәрәҗәдә колачлауны;

Республика мәктәптән тыш эш үзәге базасында мәгариф системасының савыктыру лагерьларына эшкә җибәрелә торган педагогик кадрларны укытуны;

республика профильле лагерьларына һәм сменаларга (балалар йортларында һәм мәктәп-интернатларда тәрбияләнүчеләр өчен лагерьлар һәм сменаларны кертеп) җибәрелә торган педагогик состав һәм ведомство буйсынуындагы учреждениеләр хезмәткәрләренә төп эш урыны буенча хезмәт хакын саклап калуны.

9. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесенең яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» муниципаль казна учреждениесенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

җәйге чорда балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм мәшгульлеген оештыру буенча әзерлек эшләрен;

стационар һәм палатка лагерьларын оештыру буенча әзерлек эшләрен; 2025 елның июнендә, августында спорт секцияләре эшен;

авыр тормыш һәм социаль куркыныч хәлләрдә калган балаларның ялын һәм сәламәтләндерелүен шифаханә һәм савыктыру учреждениеләре базаларында оештыруны тәэмин итәргә;

социаль реабилитациягә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждениеләрдә тәрбияләнүчеләрнең ялын һәм аларны савыктыруны оештыруны тәэмин итәргә.

10. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесенең мәдәният бүлеге» муниципаль казна учреждениесенә 2025 елның җәйге чорында сәламәтләндерү лагерьларына күчмә китапханәләр эшен оештырырга.

11. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2025 елда балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерелүен, эш

белән тәэмин ителешен оештыру Татарстан Республикасы бюджеты, Биектау муниципаль районы бюджеты, бюджеттан тыш чыганаклар, ата-аналар акчалары һәм коммерциягә карамаган оешмалар чыганаклары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

12. Район башкарма комитетының икътисад бүлегенә стационар лагерьларның профильле сменаларына юлламалар сатып алуга торглар үткәрергә.

13. Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе һәм «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Чыршы» балаларны савыктыру лагере» муниципаль бюджет учреждениесе аша Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын түләүне тәкъдим итәргә.

14. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып игълан итәргә.

15. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Сабирҗановка йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф.Хәкимуллин

1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
башкарма комитетының
2024 елның 23 декабрендә 1146нче
номерлы карары белән расланды

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында
балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру турында
нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру механизмын һәм район башкарма комитеты, җирле үзидарә органнары, дәүләт һәм дәүләтнеке булмаган учреждениеләр, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерелүен һәм мәшгульлеген оештыруда катнашучы оешмалар һәм гражданнарның үзара хезмәттәшлеге тәртибен билгели.

1.2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ялын, аларны сәламәтләндерүне һәм эш белән тәэмин итүне оештыру буенча вәкаләтле орган булып Биектау муниципаль районы балалар һәм яшьләрнең ялын, аларны сәламәтләндерүне, эш белән тәэмин итүне оештыру буенча ведомствоара комиссиясе тора. Балалар һәм яшьләрнең ялын, аларны сәламәтләндерүне, эш белән тәэмин итүне оештыру буенча ведомствоара комиссиянең эшчәнлек тәртибе һәм составы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана.

1.3. Әлеге Нигезләмә кысаларында балалар һәм яшьләрнең ялы, сәламәтләндерелүе һәм мәшгульлеге дигәндә, тиешле бюджетлар акчалары исәбеннән өлешчә яисә тулысынча финанслана торган балалар һәм яшьләрдә шәхеснең белем һәм иҗат потенциалын үстерүне, сәламәтлек саклауны һәм ныгытуны, авыруларны профилактикалауны, организмны чыныктыруны, сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләрен формалаштыруны, балигъ булмаганнарның күзәтчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалауны, җәмгыятькә файдалы һәм җитештерүчән хезмәт, физик культура, спорт, туризм һәм эшчәнлекнең башка төрләре белән шөгыльләнүне тәэмин итә торган каникуллар вакытында гамәлгә ашырылган шартлар һәм чаралар комплексы аңлашыла.

2. Балалар һәм яшьләрнең ялын, аларны сәламәтләндерүне һәм эш белән тәэмин итүне оештыру формалары

2.1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында балалар

һәм яшьләрнең ялын, аларны сәламәтләндерүне һәм эш белән тәэмин итүне оештыру түбәндәге формаларда гамәлгә ашырылырга мөмкин:

стационар лагерьда смена;

стационар лагерьда профильле смена;

палатка лагеренда профильле смена;

Кара диңгез яр буендагы стационар лагерьда профильле смена;

көндез булу лагерында (мәктәп яны) смена;

шифаханә-курорт учреждениесендә смена.

2.2. Стационар лагерьда смена – белем алучылар һәм тәрбияләнүчеләр стационар базада тәүлек буе булу белән үткәрелә торган каникул чорында балалар белән белем һәм сәламәтләндерү эшчәнлеге формасы.

2.3. Стационар лагерьда профильле смена – белем алучылар һәм тәрбияләнүчеләр тәүлек буе стационар базада булу белән үткәрелә торган, иҗади сәләтле яисә социаль актив балалар, волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый оешмалары активы белән каникул чорында гамәлгә ашырылган белем бирү һәм сәламәтләндерү эшчәнлеге формасы.

2.4. Кара диңгез яры буендагы стационар лагерьда профильле смена – белем алучылар һәм тәрбияләнүчеләр тәүлек буе Кара диңгез яр буендагы стационар базада булу белән үткәрелә торган, иҗади сәләтле яисә социаль актив балалар, волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый оешмалары активы белән каникул чорында гамәлгә ашырылган белем бирү һәм сәламәтләндерү эшчәнлеге формасы.

2.5. Палатка лагеренда профильле смена - белем алучылар һәм тәрбияләнүчеләр кыр шартларында тәүлек буе булу белән үткәрелә торган, иҗади сәләтле яисә социаль актив балалар (яшь техниклар, туристлар-туган якны өйрәнүчеләр, экологлар, спортчылар, математиклар, филологлар, журналистлар, коткаручылар, диңгезчеләр, автомобилистов, волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы, балалар иҗатының төрле төрләре буенча кышкы һәм җәйге профильле мәктәпләр һ.б. сменалары) белән каникул чорында гамәлгә ашырылган белем бирү һәм сәламәтләндерү эшчәнлеге формасы.

2.6. Көндез булу лагеренда (мәктәп яны) смена – укучыларның көндезге вакытта булуы белән һәм аларны ашатуны мәҗбүри оештыру белән үткәрелә торган гомуми белем бирү учреждениеләре һәм өстәмә белем бирү учреждениеләре укучылары белән каникул чорында, күбесенчә гомуми белем бирү учреждениеләре базасында гамәлгә ашырылган сәламәтләндерү һәм белем бирү эшчәнлеге формасы.

2.7. Шифаханә-курорт учреждениесендә смена - белем алучылар һәм тәрбияләнүчеләрнең шифаханә-курорт учреждениесендә тәүлек буе булуы белән һәм реабилитация һәм (яисә) тернәкләндереп дәвалау буенча чараларны мәҗбүри оештырып балалар һәм яшьләр белән сәламәтләндерү эшчәнлеге формасы.

2.8. Вакытлыча эшкә урнаштыру - каникул чорында аларны вакытлыча эш белән тәэмин итү һәм балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү максатларында оешмалар, предприятиеләр, учреждениеләр базасында балигъ булмаганнар белән гамәлгә ашырыла торган хезмәт һәм белем бирү эшчәнлеге формасы.

2.9. Сменалар озынлыгы ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

2.10. Сменаларны үткәрү сроклары сменаны оештыручылар тарафыннан билгеләнә.

2.11. Балалар лагерьларында отрядлар балаларның яшен һәм кызыксынуларын исәпкә алып туплана. Отрядларның саны «Балалар ялы һәм сәламәтләндерү шәһәр яны стационар учреждениеләрен оештыру, карап тоту һәм эш режимын оештыру буенча санитар-эпидемиологик таләпләр» санитар-эпидемиологик кагыйдәләр һәм нормативлары (СанПиН 2.4.4.1201-03) нигезендә билгеләнә.

## 3. Балалар һәм яшьләрнең ялы, аларны сәламәтләндерү һәм эш белән тәэмин итү кампаниясендә катнашучылар

3.1. Балалар һәм яшьләрнең ялы, аларны сәламәтләндерү һәм эш белән тәэмин итү кампаниясендә катнашучылар булып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә даими яшәүче 7 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалар тора.

3.2. Балалар һәм яшьләрнең ялын, аларны сәламәтләндерүне һәм эш белән тәэмин итүне оештыру балалар һәм яшьләрнең түбәндәге категорияләре киселешендә гамәлгә ашырыла:

гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары;

авыр тормыш хәлендә калган балалар;

ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен балалар йортларында һәм мәктәп-интернатларда тәрбияләнүчеләр;

муниципаль районның коммерциячел һәм коммерциягә карамаган оешмалары хезмәткәрләре (муниципаль һәм дәүләт учреждениеләреннән тыш) балалары;

балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясендә исәптә торучы балалар, девиант тәртипле балалар;

СВО да катнашучылар балалары.

## 4. Балалар һәм яшьләрнең ялы, аларны сәламәтләндерү һәм эш белән тәэмин итү сменаларын оештыручылар

4.1. Балалар һәм яшьләрнең ялы, сәламәтләндерелүе һәм эш белән тәэмин ителеше сменаларын оештыручылар булып (килешү буенча) Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты тора.

4.2. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгының, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының, Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының балалар һәм яшьләрнең ялы,

сәламәтләндерелүе һәм мәшгульлеге сменаларын оештыручылар буларак компетенциясе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының хокукый актлары белән билгеләнә.

4.3. Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының көндезге лагерьларында (мәктәп яны) сменаларын, муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең балалары һәм коммерцияле һәм коммерциягә карамаган оешмалар хезмәткәрләренең балалары өчен стационар лагерьларда сменаларын (дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрдән тыш), иҗади сәләтле яисә социаль актив балалар һәм волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр өчен стационар һәм палаткалы лагерьларда профильле сменалар оештыручы булып тора.

## 5. Балалар һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерелүен һәм мәшгульлеген финанслау тәртибе

5.1. Балалар һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерелүен һәм мәшгульлеген түбәндәге чыганаклардан (килешү буенча) башкарыла:

федераль бюджет акчалары;

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары;

оешмалар акчалары;

ата-аналар акчалары;

законнар белән каралган башка чыганаклар.

5.2. Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм мәшгульлеген оештыруны финанслау тәртибе, Татарстан Республикасында балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыруга хезмәт күрсәтү күләмнәре нормативларын чираттагы финанс елына сменаларны оештыручылар һәм балалар һәм яшьләрнең ялы, сәламәтләндерү һәм мәшгульлеге кампаниясендә катнашучылар киселешендә раслау, шулай ук республика бюджеты акчалары исәбеннән балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүне һәм мәшгульлеген финанслауда өлешле катнашу тәртибе һәм күләмнәре Министрлар Кабинетының хокукый актлары белән билгеләнә.

## 6. Балаларның ялы һәм сәламәтләндерелүе өчен ата-аналар түләвенең күләмен билгеләү тәртибе.

6.1. Сәламәтләндерү учреждениеләрендә балаларның ялы һәм аларны савыктыру өчен ата-аналар түләве күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының тиешле хокукый акты белән билгеләнгән һәм Татарстан Республикасында балаларны оештыруга һәм савыктыруга финанс чыгымнары нормативының 15 процентыннан ким булмаган күләмендә билгеләнә.

6.2. Балаларны сәламәтләндерү учреждениеләрендә ял итү һәм сәламәтләндерү өчен ата-аналар түләве алынмый:

авыр тормыш һәм социаль куркыныч ситуациясендә калган балалардан,

балалар йортлары һәм интернат-мәктәпләрдә тәрбияләнүчеләрдән;

хроник авырулары булган, шул исәптән аларны озата баручы ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) берсеннән;

район балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиясендә учетта торучы балалардан, үз-үзләрен тотышы девиант булган балалардан;

республика, бөтенроссия, халыкара конкурсларда, бәйгеләрдә һәм олимпиадаларда җиңүчеләрдән һәм призерлардан, СВО да катнашучылар балаларыннан.

## 7. Көндезге лагерьларда (мәктәп яны) балаларның ял һәм сәламәтләндерү сменасын оештыру тәртибе

7.1. Көндезге лагерьларга (мәктәп яны) гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары ата-аналарының (законлы вәкилләренең) гаризалары нигезендә җибәреләләр.

7.2. Ата-аналарның гаризалары укучы белем алган гомуми белем бирү учреждениесенә район башкарма комитетының мәгариф бүлеге тарафыннан расланган форма буенча тапшырыла.

7.3. Гомуми белем бирү учреждениесе ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) гаризалары нигезендә гомуми белем бирү учреждениесенең җәйге сәламәтләндерү кампаниясе өчен көндезге лагерьга (мәктәп яны) җибәрелүче балаларның җыелма исемлеген төзи, һәм җәйге сәламәтләндерү кампаниясе өчен 50 календарь көнгә кадәр; кышкы савыктыру кампаниясе өчен 30 календарь көнгә кадәр срокта аны район башкарма комитеты мәгариф бүлегенең мәктәптән тыш эш үзәгенә тапшыра.

7.4. Җыелма исемлектә күрсәтелә:

баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме;

гариза биргән ата-анасының (законлы вәкиленең) фамилиясе, исеме, атасының исеме;

баланың туган көне, ае, елы, җенесе;

ата-анасының (законлы вәкиленең) эш урыны;

бала укыган гомуми белем бирү учреждениесенең исеме;

бала укыган класс.

7.5. Район башкарма комитеты мәгариф бүлегенең мәктәптән тыш эше үзәге җәйге сәламәтләндерү кампаниясе өчен 30 календарь көнгә кадәр һәм кышкы савыктыру кампаниясе өчен 15 календарь көнгә кадәр срокта гомуми белем бирү учреждениеләре балаларының җыелма исемлекләре нигезендә муниципаль район балаларының җыелма исемлеген төзи һәм көндезге лагерьларда (мәктәп яны) ял итүне оештыру планын төзи.

7.6. Көндезге (мәктәп яны) лагерьларда балаларның ялын оештыру планы чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган муниципаль районның көндезге (мәктәп яны) лагерьларында балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүен оештыруга хезмәт күрсәтү күләмнәре нормативлары чикләрендә төзелә һәм үз эченә алырга тиеш:

базаларында көндезге лагерьлар (мәктәп яны) оештырылачак гомуми белем бирү учреждениеләре исемнәре;

гомуми белем бирү учреждениеләре киселешендә көндезге лагерьларда (мәктәп яны) оештырылган урыннар саны;

гомуми белем бирү учреждениеләре киселешендә көндезге (мәктәп яны) лагерьларында оештырылучы сменалар саны һәм аларның дәвамлылыгы;

базаларында көндезге лагерьлар (мәктәп яны) оештырылачак гомуми белем бирү учреждениеләренә һәм сменаларга балаларны бүлү.

7.7. Көндезге лагерьда (мәктәп яны) балалар ялын оештыру планнары «Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль учреждениесе боерыгы белән раслана.

7.8. Көндезге лагерьларда (мәктәп яны) җәйге һәм кышкы савыктыру кампанияләре тәмамланган көннән алып 30 көн үткәч, район башкарма комитеты мәгариф бүлегенең мәктәптән тыш эшләү үзәге көндезге лагерьларда (мәктәп яны) уздырылган сәламәтләндерү кампаниясе турында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы адресына хисап җибәрә.

## 8. Муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре балаларының ялын һәм сәламәтләндерелүен стационар лагерьларда оештыру тәртибе

8.1. Ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) берсе муниципаль яисә дәүләт учреждениесе хезмәткәре булган гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары ата-ана (законлы вәкил) эшләгән муниципаль яисә дәүләт учреждениесе аша бирелгән ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) берсенең гаризасы нигезендә стационар лагерьларга җибәрелә.

8.2. Ата-аналарның гаризалары район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге раслаган форма буенча җәйге сәламәтләндерү кампаниясе башланганчы 75 календарь көннән дә соңга калмыйча бирелә.

8.3. Муниципаль яисә дәүләт учреждениесенең вәкаләтле органы (вазыйфаи заты) стационар лагерьларга җибәрелә торган учреждение хезмәткәрләренең балаларының алдан исемлеген төзи һәм җәйге сәламәтләндерү кампаниясе башланганчы 70 календарь көннән дә соңга калмыйча күрсәтелгән беренчел исемлекне район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлегенә тапшыра.

8.4. Беренчел исемлектә күрсәтелә:

учреждениенең исеме;

баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме;

гариза биргән ата-ананың (законлы вәкилнең) фамилиясе, исеме, атасының исеме;

ата-ананың икенчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (әгәр ата-ананың икенчесе булса);

ата-ананың икенчесенең эш урыны (булганда);

баланың туган көне, ае, елы, җенесе;

бала укыган гомуми белем учреждениесенең исеме;

бала укыган класс;

җәйге савыктыру кампаниясендә баланың стационар балалар лагеренда булу ае.

8.5. Район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге учреждениеләрнең башлангыч исемлекләре нигезендә стационар лагерьларга җибәрелә торган муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре балаларының беренчел җыелма исемлекләрен төзи.

8.6. Беренчел җыема исемлектә күрсәтелә:

ата-анасының (законлы вәкиленең) эш урыны;

гариза биргән ата-ананың (законлы вәкилнең) фамилиясе, исеме, атасының исеме;

баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме;

баланың туган көне, ае, елы, җенесе;

бала укыган гомуми белем учреждениесенең исеме;

бала укыган класс;

җәйге сәламәтләндерү чорында баланың стационар балалар лагеренда булу ае.

8.7. Муниципаль яисә дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең алдан җыелма исемлеккә кертелгән стационар лагерьларга җибәрелә торган балалар санының артуы ачыкланганда, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган стационар лагерьларда муниципаль яисә дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең балаларының ялын оештыру буенча хезмәтләр күләме нормативларына карата район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге җәйге савыктыру кампаниясе башланганчы 60 календарь көннән дә соңга калмыйча, район территориясендә урнашкан муниципаль учреждениеләр һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре балаларының уртача исемлек санына пропорциональ төзелгән әлеге муниципаль яисә дәүләт учреждениеләренең стационар лагерьларга җибәрү өчен мөмкин булган иң чик санын муниципаль яисә дәүләт учреждениеләренә җиткерә.

8.8. Район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге тарафыннан агымдагы елда стационар лагерьларга җибәрү өчен мөмкин булган муниципаль яисә дәүләт учреждениесе балаларының иң чик саны кысаларында муниципаль (дәүләт) учреждениесенең вәкаләтле органы (вазыйфаи заты) стационар лагерьларга җибәрелә торган муниципаль (дәүләт) учреждение хезмәткәрләренең балалары исемлеген кабат төзи һәм кабат район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлегенә җәйге сәламәтләндерү кампаниясе башланганчы 55 календарь көннән дә соңга калмыйча җибәрә.

8.9. Район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге учреждениеләр тапшырылган (кабат тапшырылган) исемлекләр нигезендә стационар лагерьларга җибәрелә торган муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре балаларының җыелма исемлеген төзи. Җыелма исемлектә әлеге Нигезләмәнең 8.6 пунктында күрсәтелгән белешмәләр, шулай ук муниципаль бирем җиткереләчәк стационар муниципаль лагерь исеме (булганда) яисә ачык конкурс йомгаклары буенча

стационар лагерьларда балаларның ялын оештыруга юлламалар алу кирәклеге турында мәгълүмат булырга тиеш.

8.10. Район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге җәйге сәламәтләндерү кампаниясе башланганчы 45 календарь көннән дә соңга калмыйча стационар лагерьларга җибәрелә торган муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре балаларының җыелма исемлеге мәгълүматларын исәпкә алып, стационар лагерьларда аларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру планын төзи.

8.11. Муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең балаларының ялын һәм аларны савыктыруны оештыру планында түбәндәгеләр булырга тиеш:

муниципаль бирем нигезендә муниципаль яисә дәүләт учреждениеләрендә эшләүчеләрнең балалары җибәрелә торган муниципаль стационар лагерьларының исемен, урыннар санын һәм сменалар санын;

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 05.04.2013 (28.12.2013 ел редакциясендә) 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә уздырыла торган ачык конкурс нигезендә сатып алына торган стационар лагерьларда урыннар саны һәм сменаларның озынлыгы.

8.12. Муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре балаларының ялын һәм аларны савыктыруны оештыру планы «Биектау муниципаль районы башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» муниципаль учреждениеесе карары белән раслана.

8.13. Муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре балаларының стационар лагерьларда җәйге савыктыру кампаниясе тәмамланганнан соң 30 көн узгач, район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына стационар лагерьларда муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре балаларының сәламәтләндерү кампаниясе уздырылуы турында хисап җибәрә.

9. Коммерцияле һәм коммерциягә карамаган оешмалар хезмәткәрләре (дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрдән тыш) балаларының ялын һәм сәламәтләндерелүен оештыру тәртибе

9.1. Ата-анасының (законлы вәкилләренең) берсе Биектау муниципаль районы территориясендә урнашкан коммерцияле һәм коммерциягә карамаган оешмалар (алга таба – оешма) хезмәткәре (дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрдән тыш) булган гомуми белем учреждениеләре укучылары стационар лагерьларга ата-ана (законлы вәкил) эшләгән оешманың вәкаләтле органына (вазыйфаи затына) ата-аналарның (законлы вәкилләренең) берсе биргән гариза нигезендә җибәреләләр.

9.2. Ата-аналардан гариза район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге раслаган форма буенча җәйге сәламәтләндерү кампаниясе башланганчы 75 календарь көннән дә соңга калмыйча бирелә. Гаризага ата-ананың эш урыныннан баланың агымдагы елда стационар лагерьга җирле бюджет акчалары исәбеннән җибәрелмәве турында белешмә кушымта итеп бирелә.

9.3. Оешманың вәкаләтле органы (вазыйфаи заты) стационар лагерьларга җибәрелә торган оешма хезмәткәрләре балаларының беренчел исемлеген төзи һәм җәйге сәламәтләндерү кампаниясе башланганчы 70 календарь көннән дә соңга калмыйча күрсәтелгән беренчел исемлекне район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлегенә тапшыра.

9.4. Беренчел исемлектә күрсәтелә:

оешма исеме;

баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме;

гариза биргән ата-ананың (законлы вәкилнең) фамилиясе, исеме, атасының исеме;

ата-ананың икенчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме (әгәр ата-ананың икенчесе булса);

ата-ананың икенчесенең эш урыны (булганда);

баланың туган көне, ае, елы, җенесе;

бала укыган гомуми белем учреждениесенең исеме;

бала укыган класс;

җәйге сәламәтләндерү кампаниясе чорында баланың стационар балалар лагеренда булу ае.

9.5. Район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге оешмаларның башлангыч исемлекләре нигезендә стационар лагерьларга җибәрелә торган оешмалар хезмәткәрләре балаларының беренчел җыелма исемлеген төзи.

9.6. Беренчел җыелма исемлектә күрсәтелә:

ата-анасының (законлы вәкиленең) эш урыны;

гариза биргән ата-ананың (законлы вәкилнең) фамилиясе, исеме, атасының исеме;

баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме;

баланың туган көне, ае, елы, җенесе;

бала укыган гомуми белем учреждениесенең исеме;

бала укыган класс;

җәйге сәламәтләндерү кампаниясе чорында баланың стационар балалар лагеренда булу ае.

9.7. Оешмалар хезмәткәрләренең алдан җыелма исемлеккә кертелгән стационар лагерьларга җибәрелә торган балалар санының артуы ачыкланганда, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган стационар лагерьларда оешмалар хезмәткәрләре балаларының ялын оештыру буенча хезмәтләр күләме нормативларына карата район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге җәйге савыктыру кампаниясе башланганчы 60 календарь көннән дә соңга калмыйча, район территориясендә урнашкан оешмалар хезмәткәрләре балаларының уртача исемлек санына пропорциональ төзелгән әлеге оешмаларның стационар лагерьларга җибәрү өчен мөмкин булган иң чик санын оешмаларга җиткерә.

9.8. Район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге тарафыннан агымдагы елда стационар лагерьларга җибәрү өчен мөмкин булган оешманың балаларының иң чик саны җиткерелгән кысаларында оешманың вәкаләтле органы (вазыйфаи заты) стационар лагерьларга җибәрелә

торган оешма хезмәткәрләренең балалар исемлеген кабат төзи һәм кабат район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлегенә җәйге сәламәтләндерү кампаниясе башланганчы 55 календарь көннән дә соңга калмыйча җибәрә.

9.9. Оешма хезмәткәрләренең балалар исемлеген тапшырганда, аның вәкаләтле органы (вазыйфаи заты) район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлегенә оешма җитәкчесе кул куйган һәр юлламаның норматив бәясенең 42,5 проценты күләмендә стационар лагерьларга юлламалар сатып алуны өлешләп финанслауда катнашу турында оешманың гарантияле хатын җибәрә.

9.10. Район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге исемлекләр (кабат бирелгән исемлекләр) нигезендә стационар лагерьларга җибәрелә торган оешмалар хезмәткәрләре балаларының җыелма исемлеген төзи. Җыелма исемлектә әлеге Нигезләмәнең 9.6 пунктында күрсәтелгән белешмәләр, шулай ук муниципаль бирем җиткереләчәк стационар муниципаль лагерь исеме (булган очракта) яисә ачык конкурс йомгаклары буенча стационар лагерьларда балаларның ялын оештыруга юлламалар алу кирәклеге турында мәгълүмат булырга тиеш.

9.11. Район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге җәйге сәламәтләндерү кампаниясе башланганчы 45 календарь көннән дә соңга калмыйча стационар лагерьларга җибәрелгән оешмаларның җыелма исемлеге мәгълүматларын исәпкә алып, стационар лагерьларда аларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру планын төзи.

9.12. Оешмалар хезмәткәрләре балаларының ялын һәм аларны савыктыруны оештыру планында түбәндәгеләр булырга тиеш:

